Татарстан Республикасы
Әлмәт муниципаль районы Советы
К А Р А Р Ы

28 декабрь 2016 ел №142

Татарстан Республикасы Әлмәт
муниципаль районы Уставына
үзгәрешләр кертү турында

2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ санлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында»гы Федераль законга үзгәрешләр кертелү белән бәйле рәвештә, 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ санлы «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы ТР Законы, ТР Әлмәт муниципаль районы Уставының XV бүлеге нигезендә, 2016 елның 30 ноябрендәге халык тыңлаулары нәтиҗәләрен исәпкә алып,

Әлмәт муниципаль районы Советы КАРАР БИРДЕ:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Уставына үзгәрешләрне кушымта нигезендә кабул итәргә.
2. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Уставына үзгәрешләрне Россия Федерациясе Юстиция министрлыгының Татарстан Республикасы буенча идарәсенә юлларга.
3. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Уставына үзгәрешләрне, теркәгәннән соң, «Әлмәт таңнары» һәм «Альметьевский вестник» газеталарында бастырып чыгарырга, «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталы»нда (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Әлмәт муниципаль районы сайтында урнаштырырга.
4. Әлеге карар 06.10.2003 елгы 131-ФЗ санлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында»гы Федераль законның 44 нче маддәсе 8 нче кисәге нигезендә үз көченә керә.
5. Карарның үтәлешенә контрольлек итүне Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы башлыгы урынбасары Н.М. Хәйдәровага йөкләргә.

Муниципаль район башлыгы А.Р. Хәйруллин

Татарстан Республикасы Әлмәт
муниципаль районы Советының
2016 елның 28 декабрендәге
142 санлы карарына кушымта

Татарстан Республикасы
Әлмәт муниципаль районы Уставына үзгәрешләр

**1) 7 нче маддәнең 1 нче кисәген** түбәндәге эчтәлектәге 12 нче пункт белән тулыландырырга:

«12) «Россия Федерациясендә хокук бозуларны профилактикалау системасы нигезләре турында»гы Федераль законда күздә тотылган хокук бозуларны профилактикалау өлкәсендә чараларны тормышка ашыру»;

**2) 44 нче маддәнең 1 нче кисәге 8 нче пунктын** түбәндәге эчтәлектәге абзац белән тулыландырырга:

«- Россия Федерациясендә хокук бозуларны профилактикалау системасы нигезләре турында»гы Федераль законда күздә тотылган хокук бозуларны профилактикалау өлкәсендә чараларны тормышка ашыра;».

Муниципаль район башлыгы А.Р. Хәйруллин